ГЛАВА
НАБЕРЕЖНО-МОРКВАШСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
ЯР БУЕ МОРКВАШЫ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШЛЫГЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

21.11.2015 с. Набережные Моркваши 59

«2016 елга Югары Ослан муниципаль районының Яр буе Моркдашы авыл җирлеге бюджеты турында»Югары Ослан муниципаль районының Яр буе Морквашы авыл җирлеге советы карары проекты буенча гавами тыңлауларны билгеләү турында

Югары Ослан муниципаль районының Яр буе Морквашы авыл җирлегендә яшәүчеләрнең хокукларын яклау максатларында 2016 елгаЮгары Ослан муниципаль районының Яр буе Морквашы авыл җирлеге бюджеты проекты буенча фикер алышуда катнашу өчен "Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 28 статьясы һәм Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының 19 Уставы нигезендә гавами тыңлаулар үткәрү юлы белән,

Карар бирәм:

"2016 елга Югары Ослан муниципаль районының Яр буе Морквашы авыл җирлеге бюджеты турында" Югары Ослан муниципаль районының Яр буе Морквашы авыл җирлеге Советы карары проекты буенча гавами тыңлаулар үткәрүне билгеләргә.

2. Түбәндәгеләрне билгеләргә:

2.1. Үткәрү датасы һәм вакыты - 2015 елның 1 декабрендә 10.00 сәгатьтә;

2.2. үткәрү срогы - 1 көн;

2.3. Үткәрү урыны - Яр буе Морквашы авылы, Красавин урамы, 40 йорт Яр буе Морквашы авыл җирлеге Башкарма комитеты бинасында;

2.4. Фикер алышкан мәсьәлә буенча тәкъдимнәр һәм искәрмәләр тапшырыла ала торган адрес халык алдында чыгыш ясау хокукы белән тыңлауларга заявкалар бирелергә мөмкин - Яр буе Морквашы авылы, Красавин ур., 40 йорт - Яр буе Морквашы авылы Башкарма комитеты секретаре Сафиуллина Ч.Р. (эш көннәрендә - 8.00 дән 16.00 гә кадәр);

2.5. Чыгыш хокукы белән гавами тыңлауларда катнашуга заявкалар бирү срогы - 2015 елның 1 декабренә кадәр (тел 3-16-47).

3. Югары Ослан муниципаль районының Яр буе Морквашыавыл җирлеге башкарма комитетына:

«2016 елга Югары Ослан муниципаль районы Яр буе Морквашы авыл җирлеге бюджеты турында» Югары Ослан муниципаль районы Яр буе Морквашы авыл җирлегенең карары проекты буенча гамәлдәге законнар нигезендә һәм әлеге карарда билгеләнгән срокларда халык алдында тыңлаулар әзерләргә һәм уздырырга;

3.2. гавами тыңлаулар үткәрү йомгаклары буенча Югары Ослан муниципаль районы Яр буе Морквашы авыл җирлеге Советына гавами тыңлаулар беркетмәсе, гавами тыңлаулар нәтиҗәләре буенча бәяләмә, шулай ук эшләнеп беткән (үзгәрешләр кертелгән очракта) проект буенча 2016 елга Югары Ослан муниципаль районының Яр буе Морквашы авыл җирлеге бюджеты проектын тәкъдим итәргә.

4. Әлеге карарны , “2016 елга Югары Ослан муниципаль районының Яр буе Морквашы авыл җирлеге бюджеты турында” Югары Ослан муниципаль районының Яр буе Морквашы авыл җирлеге Советы карары проектын Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Югары Ослан муниципаль районы
Яр буе Морквашы авыл җирлеге башлыгы И. Х. Гаязов